# КАРАР

**“18” ноябрь 2021 ел № 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылында халык җыены нәтиҗәләре турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Иске Кишет авылында Г. Сафиуллин, Дружба, Мостовая урам-юл чолтәрендә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Иске Кишет авылында скважина өчен насос алу;
- Иске Кишет торак пунктында Дружба урамы буенча 139а йортыннан алып Г.Сафиуллин урамы киселешенә кадәр. Г. Сафиуллина урамы 39 нчы йорттан чишмәгә кадәр 6 м киңлектәге юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау;
- Иске Кишет авылындагы «Райлә» чишмәсен төзекләндерү өчен материаллар сатып алу һәм төзекләндерү ;
- янгын гидрантларына комплект җиһазлары сатып алу(1 данә янгын җиңсәсе, көчеш башламы, янгын колонкасы, янгын стволы)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 277 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 148 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 148 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыенынәтиҗәләре дөрес.
2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы

студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Иске Кишет авылында Г. Сафиуллин, Дружба, Мостовая урам-юл челтәрендә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Иске Кишет авылында скважина өчен насос алу;
- Иске Кишет торак пунктында Дружба урамы буенча 139а йортыннан алып Г.Сафиуллин урамы киселешенә кадәр, Г. Сафиуллина урамы 39 нчы йорттан чишмәгә кадәр 6 м киңлектәге юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау;
- Иске Кишет авылындагы «Райлә» чишмәсен төзекләндерү өчен материаллар сатып алу һәм төзекләндерү ;
- янгын гидрантларына комплект җиһазлары сатып алу(1 данә янгын җиңсәсе, күчеш башламы, янгын колонкасы, янгын стволы)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урында мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Минзянова